**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
(IV чакырылыш)

утыз алтынчы утырыш
**КАРАРЫ**

11 ноябрь 2024 ел **№ 282** Теләче ав.

Теләче муниципаль район Советының муниципаль
хезмәт өлкәсендә кайбер карарларының
үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 8 августындагы 09/13-09/3593 номерлы хатын карап, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, «Контракт буенча җирле администрация башлыгы муниципаль вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

А) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2014 елның 7 ноябрендәге 228 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» карары;

Б) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2015 елның 29 декабрендәге 29 номерлы «Теләче муниципаль район Советының 2014 елның 7 ноябрендәге 228 номерлы карары белән расланган Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы А. Г. Фәтхуллин